СОВЕТ
СРЕДНЕАТЫНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная , д. 2а, д.Нижние Аты,
Арский муниципальный район, 422016

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРТА АТЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урамы, 2 йорт, Түбән Аты авылы,
Арча муниципаль районы, 422016

Тел. (84366)507-35, факс (84366)507-35. E-mail: Sat .Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы**

**Урта Аты авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы**

**КАРАРЫ**

**25 октябрь 2021 ел** **№3**

**Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлеге Түбән Аты авылында гражданнарның үзарасалым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль Урта Аты авыл җирлеге Уставының 25 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы Карар бирде:

1.Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлеге Түбән Аты авылында ,Үзәк урам , 37 йорт адресы буенча гражданнарның үзарасалым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2021 елның 10 ноябрenә 13 сәгать 30 минутта халык җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлеге Түбән Аты авылында Үзәк урамы, 37 йорт адресы буенча гражданнарның үзарасалым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2021 елның 10 ноябрenә 15 сәгать 00 минутта халык җыенының икенче этабын билгеләргә.

3.Торак пункта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне территория буенча башкарырга.

1нче этап: Аты ,Үзәк,Кече урамнарда яшәүчеләр

2нче этап: И.Шәйхетдинов, Югары, Яшьләр, Туры урамнарда яшәүчеләр.

4. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 2022 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлеге Түбән Аты авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә,түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге

формада укучы студентлардан, 80 яшьтән узган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзарасалым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру
- юл-урам челтәре юл полотносын ремонтлау
- Тубән Аты авылында су башнясы өчен насос сатып алу
- Тубән Аты авылында янгын гидранты өчен колонка сатып алу

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

"ӘЙЕ" "КАРШЫ"

5. Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлеге Тубән Аты авылында гражданнарның үзарасалым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Урта Аты авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Түбән Аты авылы, Үзәк урам, 37йорт; ТР, Арча районы, Түбән Аты авылы, Үзәк урам, 11Б йорт адреслары буенча,интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Урта Аты авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Батталова